**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге советы**
**КАРАРЫ**

**“28” сентябрь 2020 ел** **№ 8**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге Советының 2013 елның 17 декабрендәге 76 номерлы «Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлегендә территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибе турында" карары белән расланган Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлегендә территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге Советының 2013 елның 30 декабрендәге 100 номерлы «Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлегендә территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибе турында" карары белән расланган Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлегендә территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертергә:

13 статьяның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыручы гражданнар җыелышының, конференцияләренең аерым вәкаләтләренә керә:

1) территориаль иҗтимагый үзидарә органнары структурасын билгеләү;

2) территориаль иҗтимагый үзидарә уставын кабул итү, аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү;

3) территориаль иҗтимагый үзидарә органнарын сайлау;

4) территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлегенең төп юнәлешләрен билгеләү;

5) территориаль иҗтимагый үзидарәнең керемнәре һәм чыгымнары сметасын һәм аның үтәлеше турындагы хисапны раслау;

6) территориаль иҗтимагый үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы хисапларны карау һәм раслау;

7) инициативалы проектны тикшерү һәм аны хуплау мәсьәләсе буенча карар кабул итү.».

2. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге Карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Кече Салтык авылы, Бакый Урманчы ур., 9 йорт;
- ТР, Кама Тамагы районы, Кече Мәрәтхуҗа авылы, Гагарин урамы, авыл клубы бинасы, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Татарстан Республикасы**
**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Кече Салтык авыл җирлеге Башлыгы,**
**Татарстан Республикасы**
**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Кече Салтык авыл җирлеге Советы рәисе** **А.Г. Җиһаншин**